КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 1 ноябрь г.Казань № 952

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле

чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 май, 481 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 май, 481 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 18 февраль, 155 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 23 май, 481 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр) бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2024 ел, 09 февраль, 72 нче

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 1 ноябрь, 952 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибе

I. Субсидия бирүнең гомуми нигезләмәләре һәм шартлары

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм контрольдә тоту чараларын үтәүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба - сайлап алуда катнашучылар) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) (алга таба - субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасы объектлары (алга таба - дәүләт исәбе һәм контроле объектлары) түбәндәгеләр була:

активлыгы минималь әһәмиятле активлыктан күбрәк яисә тигез булган һәм чагыштырма активлыгы атом энергиясен файдалану өлкәсендә федераль нормалар һәмкагыйдәләр белән билгеләнгән минималь әһәмиятле чагыштырма активлыктан күбрәк яисә тигез булган радионуклидларны үз эченә алган ачык һәм ябык радионуклид чыганакларда урнашкан радиоактив матдәләр;

эшкәртелгән атом-төш ягулыгында булган радиоактив матдәләр;

әйләнә-тирә мохиткә чыгарылмалардагы һәм ташлаулардагы радионуклидлар;

шул исәптән территорияләрнең радиацияле пычранган кишәрлекләрендә урнашкан радиоактив калдыклар;

активлыгы минималь әһәмиятле активлыктан күбрәк яисә тигез булган һәм чагыштырма активлыгы атом энергиясен файдалану өлкәсендә федераль нормалар һәмкагыйдәләр белән билгеләнгән минималь әһәмиятле чагыштырма активлыктан

күбрәк яисә тигез булган атом-төш материалларын дәүләт исәбе һәм тикшереп тору системасында исәпкә алынмый торган атом-төш материаллары.

3. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Министрлык тора.

3. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору буенча түбәндәге чараларны үтәүгә бәйле сайлап алуда катнашучыларның чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә:

эшчәлекләре Татарстан Республикасы территориясендә булган дәүләт исәпкә алуы һәм контроле объектлары (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби частьларыннан һәм оешмаларыннан тыш) белән эш итүгә бәйле оешмалардан (алга таба - оешмалар) керә торган хисапларны җыю, эшкәртү, анализлау һәм, аларның дөреслеген тикшереп торуны кертеп, гомумиләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт исәбе һәм контроле объектларын исәпкә алу һәм тикшереп тору буенча аналитик материаллар әзерләү, белешмәләр базасын булдыру һәм алып бару;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт исәбе һәм контроле объектлары буенча билгеләнгән формада хисапларны «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясендә билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, «Радиоактив калдыклар белән эш итү буенча милли оператор» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт һәм ведомство исәпкә алу һәм тикшереп тору мәгълүмат-аналитика үзәгенә (алга таба - үзәк мәгълүмат-аналитика үзәге) җибәрү (анализлаган һәм гомумиләштергәннән соң);

дәүләт исәбе һәм контроле объектларын исәпкә алу һәм контрольдә тоту мәсьәләләре буенча методик җитәкчелек итү, оешмаларга консультация ярдәме күрсәтү.

5. Субсидияләр алучыны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү алымы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) соратып алу – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып уздыру.

6. Сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

сайлап алу эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатларга туры килүе;

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны, кадрлар һәм матди-техник тәэмин итүне исәпкә алу һәм тикшереп тору өлкәсендәге эш тәҗрибәсе булу, шул исәптән:

заявка бирү датасына сайлап алу катнашучысы штатында радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасы эшләвенә бәйле мәсьәләләр буенча әзерләү, яңадан әзерләү, квалификация күтәрү узган хезмәткәр булу;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы кимендә 30 оешма булу (исәпкә алынганнардан тыш), алар өчен соңгы өч елда даими нигездә сайлап алуда катнашучы тарафыннан радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча консультацияләр гамәлгә ашырыла һәм алар радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбе һәм тикшереп тору системасына хисаплар тапшыра;

сайлап алуда катнашучының дәүләт исәбе һәм контроле объектлары белән операцияләр буенча елына оешмалар тарафыннан тәкъдим ителгән кимендә 40 эшкәртелгән хисап булу (соңгы өч елда);

сайлап алуда катнашучы үзәк мәгълүмат-аналитик үзәгенә җибәргән оешмалар тәкъдим иткән хисаплар саны (анализлаганнан һәм гомумиләштергәннән соң) - «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе билгеләгән тәртип нигезендә соңгы өч елда оешмалар тарафыннан тапшырылган һәм радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбе һәм тикшереп тору өлкәсендә гамәлдәге норматив хокукый актлар таләпләренә туры килә торган хисаплар санының 100 проценты.

7. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

8. Министрлыкның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Субсидия Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелгән килешү (алга таба - килешү) нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында йөкләмәләрне субсидия алучы тарафыннан алган очракта бирелә.

Субсидия бирү шарты булып субсидияләр алучылар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең

валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю тора.

11. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

12. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы персонал хезмәте өчен түләү фонды;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы персонал хезмәте өчен түләүгә күчерүләр;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле элемтә хезмәтләре (телефон элемтәсе, «Интернет» челтәренә керү), электрон документлар әйләнеше системасы;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгым материалларын һәм тәэмин итү предметларын сатып алу (офис кәгазе, перфорирланган папка-файл, принтер өчен картриджлар, ручкалар, маркерлар, конвертлар, степлерлар һәм башка чыгым материаллары);

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган бүлмәләр арендалау;

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашырганда кулланыла тоган коммуналь хезмәтләр.

13. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучыга бирелә торган субсидиянең күләме (Сп) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{п} = З_{п1} + З_{п2} + З_{п3} + З_{п4} + З_{п5} + З_{п6},$$

монда:

$З_{п1}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы персонал хезмәте өчен түләү фонды чыгымнары;

$З_{п2}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы персонал хезмәте өчен түләүгә күчерүләр чыгымнары;

$З_{п3}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле элемтә хезмәтләре (телефон элемтәсе, «Интернет» челтәренә керү), электрон документлар әйләнеше системасы чыгымнары;

$З_{п4}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чыгым материалларын һәм тәэмин итү предметларын сатып алу чыгымнары (офис кәгазе, перфорирланган папка-файл, принтер өчен картриджлар, ручкалар, маркерлар, конвертлар, степлерлар һәм башка чыгым материаллары);

$З_{п5}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган бүлмәләр арендалау чыгымнары;

$З_{п6}$ – Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашырганда кулланыла тоган коммуналь хезмәтләр чыгымнары.

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы субсидия алучы персоналның хезмәтенә түләү чыгымнары күләме ($З_{п1}$) расланган штат расписаниесе нигезендә персоналның исәпләнгән санынннан, исәпләнгән вазыйфаи окладларыннан һәм тариф ставкаларыннан, стимуллаштыручы башка түләүләрдән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында, субсидия алучының локаль норматив актларында каралган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын гамәлгә ашыручы персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары (Зп2) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүне кертәләр.

Бу Тәртипнең 12 пунктындагы дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән башкарылган планлаштырылган чыгымнарны исәпләүне үз эченә алган документлар нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу һәм тикшереп тору чараларын башкарганда кулланыла торган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме ($З_{п6}$) ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларга билгеләнгән коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын исәпкә алып, бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җайга салуның тиешле чорына билгеләнгән кулланучылар өчен тарифлар (бәяләр) буенча исәпләнә.

14. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча консультацияләр гамәлгә ашырылган оешмалар саны (исәптән төшерелгәннәрдән тыш) - кимендә 30;

дәүләт исәбе һәм контроле объектлары белән операцияләр буенча эшкәртелгән хисаплар саны - кимендә 40;

сайлап алуда катнашучы үзәк мәгълүмат-аналитик үзәгенә җибәргән оешмалар тәкъдим иткән хисаплар саны (анализлаганнан һәм гомумиләштергәннән соң) - «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе билгеләгән тәртип нигезендә оешмалар тарафыннан тапшырылган һәм радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбе һәм тикшереп тору өлкәсендә гамәлдәге норматив хокукый актлар таләпләренә туры килә торган хисаплар санының 100 проценты.

Килешүдә билгеләнә торган субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы субсидия бирелә торган елның 31 декабрендә билгеләнә.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

15. Сайлап алуда катнашучылар заявка каралган һәм килешү төзелгән даталарга түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормыйлар;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормыйлар;

бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агентлары булмау;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

16. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүенраслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## III. Сайлап алуны уздыру турында игълан булдыру һәм урнаштыру тәртибе

17. Сайлап алуны уздыру турында игълан Министрлык тарафыннан Министрлык “Электрон бюджет” системасында игъланны формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан һәм субсидия турындагы мәгълүматның бердәм порталында бастырып чыгарылганнан соң урнаштырыла.

18. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы

белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасын, шул ук вакытта заявкаларны кабул итеп алу тәмамлану датасы сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннең иртәгесеннән бишенче календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, Министрлыкның электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 15 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 24 – 29 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Тәртипнең 30 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 33 – 36 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 37 пункты нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

конкурста катнашучыларга әлеге Тәртипнең 31 - 32 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында игълан итүнең аңлатмаларын бирү тәртибе, мондый бирүне башлау датасы һәм тәгәлләү вакыты;

сайлап алуда җиңүче әлеге Тәртипнең 45 пункты нигезендә килешүгә кул куярга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене әлеге Тәртипнең 49 пункты нигезендә килешү төзүдән читләшкән дип тану шартлары;

бердәм порталда, шулай ук «Интернет» челтәрендә https://agro.tatarstan.ru Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алу йомгакларын үткәрү беркетмәсен урнаштыру сроклары, сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый.

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

19. Бердәм порталда сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында Министрлык тарафыннан игълан урнаштыру конкурста катнашучыларның заявкаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

20. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кире алу тора.

21. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

22. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы игълан бердәм порталда урнаштырылган көннән сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

23. Әлеге Тәртипнең 19 пункты нигезендә сайлап алуны юкка чыгару срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) белән килешү төзелгәнче Министрлык Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статья-сындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны юкка чыгарырга мөмкин.

## V. Заявкаларны формалаштыру һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирү тәртибе

24. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны, кадрлар һәм матди-техник тәэмин итүне исәпкә алу һәм тикшереп тору өлкәсендәге эш тәҗрибәсе булу, шул исәптән:

заявка бирү датасына сайлап алуда катнашучы хезмәткәрләре реестрыннан сайлап алуда катнашучының «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясендә яки радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасы эшләве белән бәйле мәсьәләләр буенча укуга лицензиясе булган башка оешмада әзерлек, яңадан әзерләү, квалификация

күтәрү үткән хезмәткәрләре турында идентификация белешмәләрне үз эченә алган өземтә;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы (исәпкә алынганнардан тыш) оешмалар исемлеге, алар өчен сайлап алуда катнашучы соңгы өч елда даими нигездә радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча консультацияләр гамәлгә ашырыла һәм алар радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбенә алу һәм тикшереп тору системасына хисаплар тапшыра, әлеге оешмалар тарафыннан «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча тапшырылган хисапларның саны дәүләт исәпкә алуы һәм радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны тикшереп тору системасының региональ мәгълүмат-аналитик үзәкләренең еллык хисаплары өчен күрсәтелә;

дәүләт исәбе һәм контроле объектлары белән операцияләр буенча елына оешмалар тарафыннан тапшырылган хисапларны сайлауда катнашучы тарафыннан эшкәртелгән хисаплар саны турында белешмәләр (соңгы өч елда);

сайлап алуда катнашучы үзәк мәгълүмат-аналитик үзәгенә җибәргән оешмалар тәкъдим иткән хисаплар саны (анализлаганнан һәм гомумиләштергәннән соң) һәм «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе билгеләгән тәртип нигезендә соңгы өч елда оешмалар тарафыннан тапшырылган һәм радиоактив матдәләрне һәм радиоактив калдыкларны дәүләт исәбе һәм тикшереп тору өлкәсендә гамәлдәге норматив хокукый актлар таләпләренә туры килә торган хисаплар саны.

25. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

26. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

27. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

28. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы булып заявкага “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

29. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

салым органында исәпкә куелу датасы һәм коды

юридик затның адресы;

элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары нигезендә сайлап алуда катнашучы гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге;

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килүенраслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәсе, соратып алына торган субсидия күләмен нигезли торган чыгымнар сметасы.

30. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

31. Бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап, сайлауның теләсә кайсы катнашучысы, сайлау тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча «Электрон бюджет» системасында тиешле гарызнамә төзү юлы белән сайлап алуны үткәрү турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында Министрлыкка иң күбе биш гарызнамә җибәрергә хокуклы.

32. Министрлык әлеге Тәртипнең 31 пунктында күрсәтелгән гарызнамәгә җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VI. Гаризаларны карау һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү кагыйдәләре

33. Заявкаларны карау «Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкаларны карау өчен аларга Министрлык керү мөмкинлеге ачылган көннән соң 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Министрлыкка «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелгән заявкаларга керү мөмкинлеге бирелә.

34. Министрлык сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик затның адресы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

35. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

36. Әгәр ул сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип танылa.

Заявканың сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карарлар заявка составында тапшырылган мәгълүматны һәм документларны сайлап алу нәтиҗәләрен тикшерү көненә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

37. Заявканы карау һәм бәяләү стадиясендә заявканы кире кагу өчен нигезләр түбәндәгеләр тора:

а) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

в) сайлап алуда катнашучы биргән заявкаларның һәм (яки) документларның сайлап алу турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

г) әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында заявка составында сайлауда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

38. Заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карау срогы тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан заявкаларны карау беркетмәсе әзерләнә, ул кергән һәм каралган заявкаларның саны

турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуның һәр катнашучысы буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә ала.

39. Заявкаларны карау беркетмәсе заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куйган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

40. Сайлау түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кире кагылган.

41. Кергән заявкаларны тәртипкә салу аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

42. Әлеге Тәртипнең 6 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче булып карап тикшерүгә тапшырылган сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче дип танылa.

43. Сайлап алуны тәгәлләү һәм анда җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм “Электрон бюджет” системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куйган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла, һәм сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла. Беркетмә түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

44. Әлеге Тәртипнең 43 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган субсидия күләмен сайлап алу йомгаклары беркетмәсендә күрсәткәндә ул сораган субсидия күләме әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибенә туры килмәгән очракта Министрлык мондый сайлауда катнашучы өчен каралган субсидия күләмен төзәтергә мөмкин, әмма ул заявкада күрсәтелгән күләмнән югарырак булмаска тиеш.

## VII. Килешү төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

45. Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре буенча сайлап алуның җиңүчесе белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә

сайлауның җиңүчесе билгеләнгәннән соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча килешү төзи.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

46. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

47. Министрлык сайлауда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве факты ачыкланган очракта яисә сайлауда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат тәкъдим ителгән очракта сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

48. Министрлык әлеге Тәртипнең 43 пунктында каралган нигезләрдә сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан очракта, килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән срокта килешүне сайлауда җиңүче итеп билгеләнмәгән очракта, Министрлык заявкасы кими төшкән тәртиптә заявкасы булган сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

49. Сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

50. Министрлык килешүләр төзүне төгәлләү срогын сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучыга субсидия бирү турында карар кабул итә, ул Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе.

51. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 эш көненнән соңга калмыйча акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

## VIII. Субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру хисабын бирү тәртибе

52. Субсидия алучы субсидияләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, «Электрон бюджет» системасында квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең типовой рәвешенә кушып бирелә торган рәвешләре буенча, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, еллык хисап хисабы субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

53. Квартал саен хисаплылыкны тикшерү Министрлык тарафыннан субсидия алучы тарафыннан тапшырылган көннән алып җиде эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Еллык хисаплылыкны тикшерү Министрлык тарафыннан субсидия алучы тарафыннан аны тапшырган көннән алып 15 эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

54. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

55. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

56. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда;

субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелмәгән һәр күрсәткече өчен биш процент күләмендә – субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта.

субсидия акчаларыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә.

57. Министрлык субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә почта аша, тапшыру турында хәбәр итү кәгазен теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, субсидия акчасын кире кайтару хакында хәбәрнамә җибәрә.

58. Субсидиянең файдаланылмаган калдыгы субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында еллык хисап бирелгән көннән һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап биргән көннән алып 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

59. Әлеге Тәртипнең 56 - 58 пунктларында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә 30 көн эчендә түләтелергә тиеш.

___